КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 24 февраль г.Казань № 135

Апас муниципаль районында җир кишәрлеген бер категориядән икенче категориягә күчерү турында

Россия Федерациясе Җир кодексы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Җирләрне яки җир кишәрлекләрен бер категориядән икенче категориягә күчерү турында» 2004 елның 21 декабрендәге 172-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьядагы 1 өлешенең 4 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Апас муниципаль районында урнашкан 4,13 гектар мәйданлы авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җир кишәрлеген 16:08:100405:163 кадастр саны белән җитештерү эшчәнлеге объектын урнаштыру максатларында сәнәгать, энергетика, транспорт, элемтә, радиотапшыру, телевидение, мәгълүмат, космик эшчәнлекне тәэмин итү җирләре, оборона җирләре, куркынычсызлыз һәм башка махсус әһәмияттәге җирләр категориясенә күчеререргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин